# “Туры сөйләмле җөмләгә синтаксик анализ” дигән темага осталык дәресе.



**Автор: Иске Өҗем урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хафизова Миләүшә Рәфкать кызы**

**Максат. Туры сөйләмле җөмләгә синтаксик анализ ясау тәртибе буенча тәҗрибә уртаклашу.**

**Файдаланылган материал.**

***Теория:*** Ф. С. Сафиуллина, М.З. Зәкиев. Хәзерге татар әдәби теле- Казан, “Мәгариф”, 2002, 385 нче бит.

Эзләнүләр һәм табышлар.- Чаллының 52 нче мәктәбе укытучысы Хәсәншинаның эш тәҗрибәсен яктырткан җыентык.

***Күнегүләр өчен.*** Я. Х. Абдрәхимова. Татар теленнән мөстәкыйль эшләү өчен күнегүләр, 7-8 нче сыйныфлар өчен- Казан, “Мәгариф”, 2005, 8-22 нче күнегүләр. 8 нче күнегү.

***Уку мәсьәләсе кую.***

**Туры сөйләмле җөмләгә анализ ясау, мондый җөмләләрне тикшерү моделен төзү.**

*Уку мәсьәләсен адымлап чишү.*

**1. Җөмләне бергәләп тикшерү.**

***“Әйдә, докторга алып барыйм”,- диде ул әтисенә.***

**Алгоритм буенча эш:**

**Җөмләне уку**
**туры сөйләмне табу**
**монда ничә җөмлә бар- табу**
**ия- хәбәрләрен табу**
**хәбәрләргә бәйләп, җөмләләргә сорау кую- баш җөмләне табу**
**җөмлә төрен билгеләү**
**бәйләүче чараны табу**
**схема төзү**

*Әйдә, докторга алып барыйм-* туры сөйләм- беренче җөмлә.
*диде ул әтисенә-* икенче җөмлә.
Сорауны икенче җөмләдән беренче җөмләгә куеп була: нәрсә диде ул әтисенә?
Беренче җөмлә- иярчен тәмамлык, икенчесе- баш җөмлә.
Бәйләүче чара- *диде* сүзе- баш җөмләнең хәбәре.




Аналитик иярчен тәмамлык җөмләле кушма җөмлә.

***Ә иртәгесен ат җиккәндә, “сугышкан” егетләр, авызга тәмәкене кыеклап кыстырып, болай сөйләшәләр:”Ә мин кичә кызмача көе су буена төшкәнмен”. (М. Мәһдиев)***

**Беренче җөмлә- баш җөмлә**

**Икенче җөмлә- туры сөйләм- иярчен рәвеш җөмлә**

**Бәйләүче чара- болай күрсәтү алмашлыгы**

**1) Баш җөмлә**

**Болай алмашлыгы**

**2) Иярчен рәвеш җөмлә**

**Аналитик иярчен рәвеш җөмләле кушма җөмлә.**

***Тик шулай да аның күңеленә “Бөтен эшне бозып ташламасын”дигән шик килде.(М. Мәhдиев***

**Беренче җөмлә- баш җөмлә**

**Икенче җөмлә- туры сөйләм- иярчен рәвеш җөмлә**

**Бәйләүче чара- дигән сүзе**

**1) Баш җөмлә**

**Дигән сүзе**

**2) Иярчен аергыч җөмлә**

**Синтетик иярчен аергыч җөмләле кушма җөмлә.**

*Бер шагыйрьнең шул хактагы шигыре искә төште:*
*Үткәннәрне уйлап үкенмәгез,*
*Онытылсын кылган ялгышлар.*
*Уфтанулар башны идермәсен:*
*Алда яшәү, алда тормыш бар...*
*(М. Маликова)*

**Беренче җөмлә- баш җөмлә**
**Икенче җөмлә- туры сөйләм- иярчен тәмамлык җөмлә**
**Бәйләүче чара- шул хактагы мөнәсәбәтле сүзе**

**1) Баш җөмлә**

**Шул хактагы мөнәсәбәтле сүзе**

**2) Иярчен тәмамлык җөмлә**

**Аналитик иярчен тәмамлык җөмләле кушма җөмлә.**

*Анда әйтте Идегәй:*
*-Үлем белән куркытмаң,*
*Курка торган уем юк!*
*(“Идегәй” дастаны)*

**Беренче җөмлә- баш җөмлә**
**Икенче җөмлә- туры сөйләм- иярчен тәмамлык җөмлә**
**Бәйләүче чара- күтәрү интонациясе**

**1) Баш җөмлә**

↑ **Күтәрү интонациясе**

**2) Иярчен тәмамлык җөмлә**

**Аналитик иярчен аергыч җөмләле кушма җөмлә.**

## Туры сөйләмле җөмлә- иярченле кушма җөмлә

**Автор сөйләме- баш җөмлә**

**Туры сөйләм- иярчен җөмлә. Төрләре:**

**Иярчен тәмамлык җөмлә. Бәйләүче чаралар: *ди, дип, диләр* сүзләре; мөнәсәбәтле сүзләр; күтәрү интонациясе**

**Иярчен аергыч җөмлә. Бәйләүче чара: *дигән* сүзе**

**Иярчен рәвеш Җөмлә. Бәйләүче чара: *болай, шулай* алмашлыклары; *дип* сүзе**